СОВЕТ НИКОЛАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНА НИКОЛАЕВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24 ноябрь,2019 ел. № 14

**КАРАР**

**Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Николаевка авыл җирлеге составына кергән Николаевка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы №131-ФЗ нең 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы №45-ЗРТ Законының 35 маддәсе нигезендә 2019 елның 15 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар түбәндәге мәсьәлә буенча җыен беркетмәсе төзелде: “2020 елда Минзәлә муниципаль районы Николаевка авыл җирлегенең Николаевка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән (көндезге формада укучы студентлардан, БВС ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, 1 һәм 2 нче төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар) 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган чараларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы?”

- торак пункт территориясендә агач кисү;
- урам исемнәре һәм йортлар нумерациясе белән күрсәткечләр сатып алу һәм урнаштыру;
- кышкы чорда юлларны грейдер белән тигезләү;
- урамнарны яктырту өчен өстәмә яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру, элек урнаштырылган яктырткычларны алыштыру.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 310 гражданнар җыенында катнашучы кертелгән,тавыш бирүдә катнашучы гражданнар җыенында катнашучылар саны 161 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“Әйе” позициясе өчен 161 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде;
“Юк” позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар чыгарды:

1.Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Николаевка авыл җирлегенең Николаевка торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен – гамәлдә дип танырга.

2.“2020 елда Минзәлә муниципаль районы Николаевка авыл җирлегенең Николаевка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән (көндезге формада укучы студентлардан, БВС ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, 1 һәм 2 нче төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш) 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган чараларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы?” соравы буенча карарны танырга һәм алынган чараларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә”:

- торак пункт территориясендә агач кисү;
- урам исемнәре һәм йортлар нумерациясе белән күрсәткечләр сатып алу һәм урнаштыру;
- кышкы чорда юлларны грейдер белән тигезләү;
- урамнарны яктырту өчен өстәмә яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру, элек урнаштырылган яктырткычларны алыштыру.

3.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Николаевка авыл җирлеге Советының мәгълүмати стендларында, Минзәлә муниципаль районы сайтында: http://menzelinsk.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы һәм http://pravo.tatarstan Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматенең рәсми порталы составында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Гамәлдәге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Николаевка авыл җирлегенә җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: ____________ М.М.Боков

Николаевка авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе: ____________ А.М.Нуриев

Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Николаевка авыл җирлегенең Николаевка торак пунктында

## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

24 ноябрь,2019 ел. № 3

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы №131-ФЗ нең 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы №45-ЗРТ Законының 35 маддәсе нигезендә 2019 елның 10 ноябрендә Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Николаевка авыл җирлегенең Николаевка торак пунктында гражданнар җыены узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге мәсьәлә буенча

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2020 елда Минзәлә муниципаль районы Николаевка авыл җирлегенең Николаевка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән (көндезге формада укучы студентлардан, БВС ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, 1 һәм 2 нче төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар) 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган чараларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт территориясендә агач кисү;
- урам исемнәре һәм йортлар нумерациясе белән күрсәткечләр сатып алу һәм урнаштыру;
- кышкы чорда юлларны грейдер белән тигезләү;
- урамнарны яктырту өчен өстәмә яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру, элек урнаштырылган яктырткычларны алыштыру.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: ____________ М.М.Боков

Николаевка авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе: ________ А.М.Нуриев